**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 14**

Кәрәкәшле ав. «18» июль 2024 ел

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле
авыл җирлеге Советының 2016 елның
28 мартындагы 7 санлы карарының
үз көчен югалтуын тану турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге 50-ТРЗ санлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2016 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында белешмәләр бирү хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләрдә 7 санлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 августындагы 10 санлы, 2023 елның 28 ноябрендәге 36 санлы, 2023 елның 15 декабрендәге 42 санлы карар редакиясендә)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча һәм Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев